**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«26» апрельда 2021 ел                                                                                № 7/1

«Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Комсомол авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2019 елның 5 дикабердәге 11/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.5 статьясы 2 өлешенә һәм 266.1 статьясына кертелгән үзгәрешләр нигезендә

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 5 декабдәге «Әҗмәкәй авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 11/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

- «Комсомол авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»нең 31 статьяның 5 абзацын: «Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны районның контроль-хисап палатасына аңа бәяләмә әзерләү өчен агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра. Бюджет үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализны үз эченә алган аңа аңлатма язуы, дәүләт (муниципаль) заданиесенең үтәлеше һәм (яки) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр, бюджет үтәлеше хакында закон (карар), тиешле бюджет үтәлеше һәм тиешле берләштерелгән бюджет үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган, авыл җирлеге Советына тапшырылырга тиешле башка документлар бирелә. Авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган срокта башкарыла. Авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә районның контроль-хисап палатасы тарафыннан авыл җирлеге Советына, бер үк вакытта авыл җирлеге Башкарма комитетына юнәлтеп бирелә».
- «Комсомол авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»нең 33 статьясын: «Муниципаль финанс тикшерүе объектлары (алга таба - контроль объектлары) булып торалар:
- бюджет акчаларын төп бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);
- максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирелгән финанс органы;
- муниципаль учреждениеләр;
- муниципаль унитар предприятиеләр;
- устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашуы белән

хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең устав (җыелма) капиталларында өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары;

- юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, дәүләт корпорацияләреннән (компанияләреннән), гавами-хокукый компанияләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашуы белән хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең устав (җыелма) капиталларында өлеше (кертеме) булган коммерция оешмаларыннан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар, алар:

- авыл җирлеге бюджетыннан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр) һәм муниципаль контрактлар нигезендә авыл җирлеге бюджетыннан акчалар, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр булып торалар;

- авыл җирлеге бюджетыннан акча бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) һәм муниципаль контрактларны үтәү максатында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) (аларга федераль законнар нигезендә финанс органнарында шәхси счетлар ачылган) буенча башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар) булып торалар.

Контроль объектларына (бюджет процессында катнашучылардан, бюджет һәм автоном учреждениеләрдән, муниципаль унитар предприятиеләрдән, гавами-хокукый компанияләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашуы белән хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең устав (җыелма) капиталларында өлеше (кертеме) булган коммерция оешмаларыннан тыш) муниципаль финанс контроле алар тарафыннан бюджеттан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр) һәм муниципаль контракт, шулай ук әлеге шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатында төзелгән контрактларны (шартнамәләрне, килешүләрне) һәм муниципаль контрактларны үтәү өлешендә, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, күрсәтелгән юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчаларын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү бюджет акчаларын баш бүлүчеләрне (бүлүчеләрне), бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларын, бюджеттан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр), муниципаль контрактлар төзегән бюджет акчаларын алучыларны тикшерү барышында яки аны тәмамлаганнан соң, күрсәтелгән бюджет процессында катнашучыларны тикшерү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Район бюджетыннан максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне, башка бюджетара трансфертларны, бюджет кредитларын бирү максатлары, тәртибе һәм шартлары үтәлешенә, шулай ук аларны бирү турында шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын һәм күрсәтелгән бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булган контрактлар (шартнамәләр, килешүләр) шартлары үтәлешенә муниципаль контроль күрсәтелгән бюджетара трансфертлар бирелгән муниципаль берәмлекнең муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла:

- максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар; бюджет кредитлары биргән район бюджеты акчаларының баш администраторлары (администраторлары);

- максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар; бюджет кредитлары бирелгән район бюджеты акчаларының баш администраторлары (администраторлары) һәм финанс органнары, шулай ук юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр.

Контроль объектлары һәм аларның вазыйфаи затлары муниципаль финанс контроле органнарына алар соравы буенча муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны үз вакытында һәм тулы күләмдә тапшырырга, муниципаль финанс тикшерүе органнарының вазыйфаи затларына

контроль объектлары территорияләренә һәм биналарына керергә рөхсәт бирергә, аларның законлы таләпләрен үтәргә тиеш.

Контроль объектларының әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны, документларны һәм материалларны муниципаль финанс контроле органнарына тапшырмавы яки вакытында тапшырмавы, шулай ук аларны тулы булмаган күләмдә тәкъдим итү яисә дөрес булмаган мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшыру, муниципаль финанс тикшерүе органнарының вазыйфаи затларының законлы эшчәнлегенә комачаулау Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе О.В. Сурова

Совет КОМСОМОЛЬСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021601373375
р 05-11800/09
ИНН 1639009641